МИНИСТЕРСТВО
ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**19.10.2016** г.Казань № **П-218**

**Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советы турында**

“Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында” 22 июль, 2005 ел, № 116-ФЗ Федераль законның 13 статьясындагы 10 өлеше, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы белән идарә итү буенча аерым вәкаләтләр тапшыру турында” 18 апрель, 2016 ел, № 249 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча вәкаләтләр тапшыру турында 05 сентябрь, 2016 елгы № С-582-АЦ/Д14 килешү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 08 октябрь, 2016 ел, № 728 карары нигезендә,

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1.Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советын оештырырга.

2. Экспертлар советы турында нигезләмәне (№1 кушымта) һәм аның составын (№2 кушымта) расларга.

3. Бу боерык имза салынганнан соң үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары – министр Р.А. Шәйхетдинов**

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының
«19» октябрь, 2016 ел
№ _____ боерыгына №1 кушымта

**Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советы (алга таба – экспертлар советы) коллегиаль орган булып тора һәм ул даими нигездә эшли.

2. Экспертлар советы составы Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы боерыгы белән раслана.

## II. Экспертлар советы вәкаләтләре

3. Экспертлар советы, “Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында” 22 июль, 2005 ел, № 116-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә:

а) Федераль законның 13 статьясына туры китереп, махсус икътисадый зона статусын алырга ниятләүче затлар тарафыннан тапшырылган бизнес-планнарны бәяли һәм бизнес-планны бәяләү нәтиҗәләре буенча бизнес-планны хуплау яки бизнес-планны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә;

б) Федераль законның 13 статьясындагы 12 өлешенә туры китереп, махсус икътисадый зона резиденты статусын алырга ниятләп, Федераль законда билгеләнгән тәртиптә эшчәнлек алып бару турында килешү төзүгә заявка тапшырган затка бизнес-планга үзгәрешләр кертү буенча бер яки берничә бурыч йөкләү турында карар кабул итә;

в) махсус икътисадый зона резидентының бизнес-планы үзгәртелүенә бәйле рәвештә эшчәнлек алып бару турында килешү шартларын үзгәртү турында гариза белән мөрәҗәгате нигезендә, Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешенә туры китереп, бизнес-планны хуплау яки бизнес планны хуплаудан баш тарту турында, шулай ук Федераль законның 18 статьясындагы 5 өлешенә туры китереп, бу резидентка бизнес-планына үзгәрешләр кертү буенча бер яки берничә бурычны йөкләү турында карар кабул итә;

г) Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенә туры китереп, Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасында фәнни-техник продукция җитештерү турында карар кабул итә.

## III. Экспертлар советы составы һәм аның эшен оештыру

4. Экспертлар советы составына федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан

Республикасында җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук коммерцияле һәм коммерциясез оешмалар вәкилләре керә.

5. Экспертлар советы экспертлар советы рәисеннән, экспертлар советы секретаре һәм әгъзаларыннан тора. Экспертлар советы составы ким дигәндә 7, күп дигәндә 20 кешедән торырга тиеш. Экспертлар советы рәисе Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

6. Экспертлар советы утырышларына материаллар әзерләү өчен экспертлар советы эшен оештыру һәм тәэмин итү өчен экспертлар советы рәисе яки рәис урынбасары тарафыннан эш төркемнәре булдырылырга мөмкин, аларның эшчәнлегенә, экспертлар советы әгъзалары белән беррәттән, экспертлар советы составына кермәүче экспертлар да җәлеп ителергә мөмкин.

7.Экспертлар советы карарлары утырышларда кабул ителә, алар кирәк булуга карап үткәрелә.

Тиешле тәртиптә билгеләнгән экспертлар советы әгъзаларының гомуми саныннан ким дигәндә яртысы катнашкан очракта, экспертлар советы утырышы, узды, дип санала.

Экспертлар советы утырышын экспертлар советы рәисе алып бара яки, ул югында, утырышта катнашкан экспертлар советы әгъзаларыннан утырышта рәислек итүче билгеләнә.

8. Экспертлар советы карарлары утырышта катнашкан экспертлар советы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, экспертлар советы рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

Утырышта экспертлар советының һәр әгъзасы телдән яки язмача рәвештә үзенең аерым бер үзгә фикерен җиткерүгә хокуклы, бу фикер экспертлар советы утырышы беркетмәсендә чагылдырыла.

9. Экспертлар советының карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашкан экспертлар советының барлык әгъзалары кул куя һәм алар экспертлар советы рәисе тарафыннан раслана.

10. Экспертлар советы карарлары, күзгә-күз очрашу үткәрелмичә генә, читтән торып тавыш бирү юлы (сорашып-белешү юлы) белән дә кабул ителергә мөмкин. Бу Нигезләмә максатында күзгә-күз очрашу төшенчәсе җыелыш үткәрү урынында экспертлар советы әгъзаларының уртак рәвештә катнашуын яки видеоконференц-элемтә аша яисә экспертлар советының барлык әгъзаларына реаль вакыт режимында берсен-берсе күрү һәм ишетү мөмкинлеге бирердәй башка төрле ысул белән оештырылган җыелышны үткәрү урынында экспертлар советы әгъзаларының уртак катнашуын аңлата.

11. Экспертлар советы карарлары Федераль закон нигезендә билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына җибәрелә.

12. Экспертлар советының эш регламенты экспертлар советы тарафыннан раслана.

13. Экспертлар советы эшчәнлегенең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы тарафыннан хәл ителә.

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының
«19» октябрь, 2016 ел
№ _____ боерыгына №2 кушымта

**Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә булдырылган “Иннополис” техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасының экспертлар советы составы**

| | |
|---|---|
| ШӘЙХЕТДИНОВ Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры, экспертлар советы рәисе |
| АФАНАСЬЕВ Михаил Павлович | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы хакимияте башлыгы (килешенү буенча) |
| ӘХМИЕВА Эльмира Әхтәм кызы | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Төбәкләрне үстерү департаменты директоры урынбасары (килешенү буенча) |
| ВАНДЮКОВ Дмитрий Владимирович | Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| ДЬЯЧКОВ<br>Виктор Васильевич | «АйСиЭл - КПО ВС» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешенү буенча) |
| ЗИАТДИНОВ<br>Марат Галимҗан улы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы хакимияте башлыгы (килешенү буенча) |
| ИВАНОВ<br>Егор Александрович | “Иннополис шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| МИЛЯВСКИЙ<br>Виталий Владимирович | “Махсус икътисадый зоналар” акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешенү буенча) |
| МИҢНУЛЛИНА<br>Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасы Инвестицияләрне үстерү агентлыгы җитәкчесе (килешенү буенча) |
| НОСОВ<br>Игорь Николаевич | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешенү буенча) |
| СВЯТОВ<br>Максим Александрович | Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының Халыкара хезмәттәшлек департаменты киңәшчесе (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| СЕМЕНИХИН Кирилл Владимирович | “Иннополис университеты” югары белем бирү автоном коммерциясез оешма директоры (килешенү буенча) |
| СУББОТИНА Ирина Петровна | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм архитектура сәясәте бүлеге начальнигы урынбасары (килешенү буенча) |